Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының егерме беренче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

11 ноябрь, 2022 ел № 52

Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 109 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 34 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Ленино-Кокушкино авыл җирлегендә халык җыенын Ленино-Кокушкино авылы территориясендә билгеләргә. Яр буе урамы гражданнары җыенын 2022 елның 30 ноябрендә Яр буе урамы буенча 1 нче номерлы йорт янында 15.00 сәгатьтә үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2023 елда Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Ленино-Кокушкино авылы Яр буе урамы гражданнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов